**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИЛДЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**КАРАР**

18.09.2018 ел. Иске Илдерәк авылы №-30

**Референдум уткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге карары:

1.Җирле референдум уткәрү инициативасы:

"2019 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

суүткәргечне агымдагы ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм ЭЦВ суга батыру скважина насосын сатып алу.

2. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

юл япмасына ком һәм вак таш салу;

- кышкы чорда торак пунктларда автомобиль юлларын тоту.

3. Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Иске Илдерәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

ӘЙЕ, ЮК

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегенең мәгълумати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы В.К. Альметкин